РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

РЕШЕНИЕ                                                    КАРАР

2022 елның 9 сентябре                                   № 19

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Кукмара шәһәре җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 1 өлешендә:

а) 5 пунктта «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы өчен» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында» сүзләренә алмаштырырга;

б) 21 пунктта «аларның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру» сүзләрен «аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәү тора торган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру»;

в) түбәндәге эчтәлекле 22.1 һәм 22.2 пунктларын өстәргә:

«22.1) составында җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан участок урманчылыклары төзелә торган урманчылыкларны төзү, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында карарлар кабул итү, шулай ук җирлекнең торак

пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын эшләү һәм раслауны тормышка ашыру;

22.2) җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыру;»

в) 40 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

40) җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләрнең үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

1.2. 48 статьяның 1 өлешендә:

а) 3 пунктны түбәндәге эчтәлекле дүртенче һәм бишенче абзацлар белән тулыландырырга:

«составында җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан участок урманчылыклары төзелә торган урманчылыкларны төзү, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында карарлар кабул итә, шулай ук җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын эшләү һәм раслауны тормышка ашыра;

җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыра;»;

б)4 пунктның өченче абзацында «муниципаль торак фонды яшәү өчен яраксыз» сүзләрен «муниципаль һәм шәхси торак фонды яшәү өчен яраксыз, барлык торак урыннары Россия Федерациясе яки Татарстан Республикасы милкендә булган күпфатирлы йортлардан тыш, күпфатирлы йортлар авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 пунктның сигезенче абзацында «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы өчен» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 пунктның унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләрнең үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;»

д) 7 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен эшли, анның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәү тора торган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне, күрсәтелгән кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру, шулай ук җирлекнең торак пунктлары чикләрендә урнашкан шәһәр урманнарыннан, аеруча саклана торган табигать территорияләреннән файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан торгызуны оештыруны гамәлгә ашыра;

1.3. 83 статьяның 7 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзацны өстәргә: «Россия Федерациясен милли үстерү максатларын һәм аларга ирешү буенча гавами хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документларда;»;

б) өченче –җиденче абзацларны дүртенче – сигезенче абзацлар дип санарга;

2. Әлеге карар, әгәр үз көченә керүнең башка сроклары законнарда каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, рәсми рәвештә халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң, әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, интернет-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре территориясендә мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев